ОНТОГЕНЕЗ — онтогенез (организмнарның индивидуаль үсеш процессы)
ОПАХАЛО ПЕРА — каурый җилпәзәсе
ОПЕРЕНИЕ — каурый чыгу, мамык-каурый белән каплану
ОРЁЛ-БЕРКУТ — бөркет
ОРЁЛ-КАРЛИК — кәрлә бөркет
ОРЁЛ-МОГИЛЬНИК — каберлек бөркете, каракош
ОРЁЛ-СКОМОРОХ — сәйяр бөркет
ОРЁЛ СТЕПНОЙ — дала бөркете
ОРЁЛ-ЯЙЦЕЕД — күкәйашар бөркет
ОРЕХОВКА (*кедровка*) — чикләвек чыпчыгы
ОРЛАН — диңгез бөркете
ОРЛАН БЕЛОГОЛОВЫЙ — ак башлы диңгез бөркете
ОРЛАН БЕЛОПЛЕЧИЙ — ак иңсәле диңгез бөркете
ОРЛАН-БЕЛОХВОСТ — ак койрыклы диңгез бөркете
ОРЛАН-ДОЛГОХВОСТ — озын койрыклы диңгез бөркете
ОРНИТОЗЫ — орнитозлар (кошларда вируслы инфекцион авырулар)
ОРНИТОЛОГИЧЕСКИЕ ЖУРНАЛЫ — орнитология журналлары
ОРНИТОЛОГИЧЕСКОЕ ОБЩЕСТВО — орнитологлар җәмгыяте
ОРНИТОЛОГИЯ — орнитология (кошларны өйрәнүче фән)
ОРНИТОФАГИ — кошашарлар
ОРНИТОФИЛИЯ— орнитофилия (үсемлекләрнең кошлар ярдәмендә серкәләнүе)
ОРНИТОХОРИЯ — орнитохория (орлыкларның кошлар ярдәмендә таралуы)
ОСЕДЛЫЕ ПТИЦЫ — утрак кошлар
ОСНОВНАЯ ВИСОЧНАЯ КОСТЬ — төп чигә сөяк
ОСНОВНАЯ КЛИНОВИДНАЯ КОСТЬ — чөйсыман төп сөяк
ОСОЕД — шөпшәашар, шөпшә кошы (карчыгалар төре)
ОСОЕДЫ — шөпшәашар карчыгалар
ОСОЕД ХОХЛАТЫЙ — бүрекле шөпшәашар
ОСТРОКЛЮВКА БУРАЯ — коңгырт очлытомшык
ОЦЕПЕНЕНИЕ ПТИЦ — кошларның катып калуы
ОЧИН — каләмлек (каурыйның җилпәзәсез өлеше)



## П

ПАВЛИН — тавис кош
ПАВЛИН АФРИКАНСКИЙ — Африка тавис кошы
ПАВЛИН ИНДИЙСКИЙ — һинд тавис кошы
ПАЛАМЕДЕЯ РОГАТАЯ — мөгезле паламедея
ПАЛАМЕДЕЕВЫЕ — паламедеялар (казсыманнардан)
ПАРАБРОНХИ — өченчел бронхлар
ПАРЕНИЕ — канат какмыйча очу
ПАРЕНИЕ ДИНАМИЧЕСКОЕ — канат какмыйча очып бару
ПАРЕНИЕ СТАТИЧЕСКОЕ — канат какмыйча "эленеп" тору
ПАСТУШКОВЫЕ — сазлык көтүчеләре
ПАСТУШКОВЫЕ ЖУРАВЛИ (*арамы*) — көтүче торналар, арàм торналар
ПАСТУШКОВЫЕ КУРОПАТКИ (*монии*) — көтүче көртлекләр, сазлык көртлекләре, монилар
ПАСТУШОК — көтүче
ПАСТУШОК ОКИНАВСКИЙ — Окинава көтүче кошы
ПАСТУШОК ТАКАХЕ (*новозеландская султанка*) — такахе көтүчесе, Яңа Зеландия солтан кошы
ПЕВЧИЕ ВОРОБЬИНЫЕ (*певчие птицы*) — сайрар чыпчыклар, сайрар кошлар (чыпчыксыманнар отрядының асотряды)
ПЕВЧИЙ ДРОЗД — сайрар миләш чыпчыгы
ПЕВЧИЕ МЫШЦЫ — сайрау мускуллары
ПЕГАНКИ — пеганкалар (үрдәк кошлар семьялыгыннан)
ПЕЛИКАН — бабакош
ПЕЛИКАН КУДРЯВЫЙ — бөдрә бабакош
ПЕЛИКАН ОЧКОВЫЙ — күзлекле бабакош
ПЕЛИКАНОВЫЕ — бабакошлар (семьялык)
ПЕЛИКАНООБРАЗНЫЕ (*веслоногие*) — бабакошсыманнар, (ишкәгаяклылар)
ПЕЛИКАН РОЗОВЫЙ — алсу бабакош
ПЕНИЕ ПТИЦ — кошлар сайравы
ПЕНОЧКА-ВЕСНИЧКА — язгы нарат чыпчыгы
ПЕНОЧКА ЗЕЛЁНАЯ — яшел нарат чыпчыгы
ПЕНОЧКА-ПЕРЕСМЕШКА — үртәүче нарат чыпчыгы
ПЕНОЧКА-ТЕНЬКОВКА — нарат күләгә чыпчыгы
ПЕНОЧКА-ТРЕЩОТКА (*желтобровка*) — чәрелдәвек нарат чыпчыгы, сарыкаш
ПЕНОЧКИ — нарат чыпчыклары
ПЕРЕВОЗЧИК — ташучы кош

ПЕРЕЛЁТНЫЙ ИНСТИНКТ — күчү инстинкты
ПЕРЕЛЁТНЫЕ ПТИЦЫ — күчмә кошлар
ПЕРЕЛЁТЫ ПТИЦ — кошларның күчеше
ПЕРЕПЕЛ (*перепёлка*) — бүдәнә, бытбылдык
ПЕРЕПЕЛЯТНИК (*малый ястреб*) — бүдәнә карчыгасы, кечкенә карчыга
ПЕРЕСМЕШНИКОВЫЕ — үртәүче чыпчык кошлар (семьялык)
ПЕРЕХОДНЫЙ ГОДОВОЙ НАРЯД — еллык күчеш купшылыгы
ПЕРЬЯ КОНТУРНЫЕ — контур каурыйлары
ПЕРЬЯ КРОЮЩИЕ — өске каурыйлар, каплама каурыйлар
ПЕРЬЯ МАХОВЫЕ — кагыну каурыйлары, чалгый каурыйлар
ПЕРЬЯ НИТЕВИДНЫЕ — җепсыман каурыйлар
ПЕРЬЯ ПУХОВЫЕ — мамык каурыйлар
ПЕРЬЯ РУЛЕВЫЕ — руль каурыйлары
ПЕСОЧНИК БЕЛОХВОСТЫЙ — ак койрыклы ком шөлдие
ПЕСОЧНИК ИСЛАНДСКИЙ — Исландия ком шөлдие
ПЕСОЧНИК-КРАСНОШЕЙКА — кызыл муенлы ком шөлдие
ПЕСОЧНИК МОРСКОЙ — диңгез ком шөлдие
ПЁСТРЫЙ ДРОЗД (*земляной дрозд*) — чуар миләш чыпчыгы
ПЕСЧАНКА — ком шөлдие
ПЕТУХ — әтәч
ПЕЧНИКИ — мичтәй оялы чыпчыклар
ПЕЧНОЙ ИГЛОХВОСТ — мичче энәкойрык
ПИГАЛИЦА (*чибис*) — тәкәрлек
ПИГМЕНТАЦИЯ ПЕРА — каурый пигментациясе
ПИГОСТИЛЬ (*копчиковая кость*) — койрык сөяге, койрыкча
ПИНГВИН АДЕЛИ — Адель пингвины
ПИНГВИН ГАЛАПАГОССКИЙ — Галапагос пингвины
ПИНГВИН ИМПЕРАТОРСКИЙ — император пингвины
ПИНГВИН КОРОЛЕВСКИЙ — затлы пингвин
ПИНГВИН ОЧКОВЫЙ — күзлекле пингвин
ПИНГВИНООБРАЗНЫЕ — пингвинсыманнар (отряд)
ПИСКУЛЬКА — чыелдык (елак) үрдәк
ПИТЕКОФАГИ — маймылашар кошлар
ПИТТОВЫЕ — питтилар (чыпчыксыманнар отрядыннан)
ПИЩУХА — чыелдык (чыпчыксыманнар отрядыннан)
ПИЩУХОВЫЕ — чыелдык чыпчыклар (семьялык)
ПЛАВАТЕЛЬНАЯ ПЕРЕПОНКА — йөзү элпәсе (кошлар аягында)
ПЛАВАЮЩЕЕ ГНЕЗДО — йөзмә оя
ПЛАВУНЧИК КРУГЛОНОСЫЙ — түгәрәк борынлы йөзгәләк шөлди



ПЛАВУНЧИК ПЛОСКОНОСЫЙ — яссы борынлы йөзгәләк шөлди
ПЛАСТИНЧАТОКЛЮВЫЕ (*гусеобразные*) — пластинка томшыклылар, казсыманнар (отряд)
ПЛЕЧЕВЫЕ ПЕРЬЯ — иңбаш каурыйлары
ПЛЮСНА — табан сөякләре
ПОГАДКИ — тизәксыман бүлентек (авыз аша чыгарып ташлана торган, эшкәртелеп бетмәгән азык калдыклары)
ПОГАНКА БОЛЬШАЯ (*чомга*) — зур чомга (үрдәк кошлар семьялыгыннан)
ПОГАНКА КРАСНОШЕЙНАЯ — кызыл муенлы чомга
ПОГАНКА СЕРОЩЁКАЯ — соры яңаклы чомга
ПОГАНКА ЧЕРНОШЕЙНАЯ — кара муенлы чомга
ПОГОНЫШ — кугыч (торнасыманнар отрядыннан)
ПОГОНЫШ БЕЛОКРЫЛЫЙ — ак канатлы кугыч
ПОГОНЫШ МАЛЫЙ — кечкенә кугыч
ПОГОНЫШИ — кугычлар, сазлык көтүчеләре
ПОДКЛЮВЬЕ — томшык асты
ПОДОРЛИК БОЛЬШОЙ — кычкыручан зур бөркет
ПОДОРЛИК МАЛЫЙ — кычкыручан кечкенә бөркет
ПОДОРЛИКИ-КРИКУНЫ — вак бөркетләр
ПОДОРОЖНИК — юлчы солы чыпчыгы
ПОДОТЕКА — арткы очлыкларның мөгезләч япмасы
ПОДСКОРЛУПОВАЯ ОБОЛОЧКА — йомырканың кабык асты сүрүе
ПОДХВОСТЬЕ — койрык асты
ПОЛЁТ — очу, очып бару
ПОЛЁТ АКТИВНЫЙ — актив очу (канат кагып)
ПОЛЁТ-БЕГСТВО — качышлы очу
ПОЛЁТ ВИБРАЦИОННЫЙ — тирбәнеп очу
ПОЛЁТ ПАССИВНЫЙ (*планирующий*) — салмак очып түбәнәю
ПОЛЁТ ПОИСКОВЫЙ — эзләнмә очыш
ПОЛЁТ ПРЕРЫВИСТЫЙ — өзекле очыш
ПОЛЁТ РАЗВЕДЫВАТЕЛЬНЫЙ — күзәтү очышы
ПОЛЁТ ТРАНЗИТНЫЙ — транзит очыш
ПОЛЁТ ТРЕПЕЩУЩИЙ — тирбәлеп очу
ПОЛИГАМНЫЕ ПТИЦЫ — полигам кошлар (берничә ана зат белән яшәүче ата кошлар)
ПОЛНАЯ ЛИНЬКА — тулысынча каурый алмаштыру
ПОЛОВОЗРЕЛОСТЬ ПТИЦ — кошларның җенси өлгергәнлеге
ПОЛУЛАПЧАТЫЕ ГУСИ — ярымтәпиле казлар
ПОМОРНИК ДЛИННОХВОСТЫЙ — озын койрыклы үләксә акчарлагы

ПОМОРНИК КОРОТКОХВОСТЫЙ — кыска койрыклы үләксә акчарлагы
ПОМОРНИК СРЕДНИЙ — уртача зурлыктагы үләксә акчарлагы
ПОПОЛЗЕНЬ — үрмәләч
ПОПОЛЗНЕВЫЕ — үрмәләч кошлар (семьялык)
ПОПУГАЕВЫЕ — тутый кошлар (семьялык)
ПОПУГАЙ — тутый кош
ПОПУГАЙ АМАЗОНСКИЙ — Амазонка тутый кошы
ПОПУГАЙ АРА — ара тутый кошы
ПОПУГАЙ БЛАГОРОДНЫЙ (*ожерельевый*) — гүзәл тутый кош
ПОПУГАЙ ВИСЯЧИЙ СИНЕГОЛОВЫЙ — зәңгәр башлы асылма тутый кош
ПОПУГАЙ ВОЛНИСТЫЙ — дулкынлы тутый кош
ПОПУГАЙ ДЯТЛОВЫЙ — тукрансыман тутый кош
ПОПУГАЙ КАРЛИКОВЫЙ МАЛЫЙ — кәрлә вак тутый кош
ПОПУГАЙ КАРОЛИНСКИЙ — Каролина тутый кошы
ПОПУГАЙ КЕРМАДЕКСКИЙ — кермадек тутый кошы
ПОПУГАЙ КЛИНОХВОСТЫЙ — чөй койрыклы тутый кош
ПОПУГАЙ КОРОТКОХВОСТЫЙ — кыска койрыклы тутый кош
ПОПУГАЙ КРАСНОХВОСТЫЙ (*пиррхура*) — кызыл койрыклы тутый кош, пиррхура
ПОПУГАЙ ЩЁТКОЯЗЫЧНЫЙ — щётка телле тутый кош
ПОПУГАЙ МАВРИКИЙСКИЙ — Маврикий тутый кошы
ПОПУГАЙ-МОНАХ — монах-тутый кош
ПОПУГАЙ-НЕРАЗЛУЧНИК — аерылмас тутый кош
ПОПУГАЙ НОЧНОЙ — төнге тутый кош
ПОПУГАЙ ОЖЕРЕЛЬЕВЫЙ КРАМЕРА — Крамер муенсалы тутый кошы
ПОПУГАЙ ПЛОСКОХВОСТЫЙ — яссы койрыклы тутый кош
ПОПУГАЙ РАЙСКИЙ — җәннәт тутый кошы
ПОПУГАЙ РАКЕТОХВОСТЫЙ ЛУСОНСКИЙ — ракета койрыклы лусон тутый кошы
ПОПУГАЙ СЕРЫЙ (*жако*) — соры тутый кош, жако
ПОПУГАЙ СИНЕГОРЛЫЙ — зәңгәр бугазлы тутый кош
ПОПУГАЙ СОВИНЫЙ (*какапо*) — ябалаксыман тутый кош, какапо
ПОПУГАЙ ФИДЖИЙСКИЙ БЛЕСТЯЩИЙ — Фиджи ялтыравык тутый кошы
ПОПУГАЙЧИК ЗЕМЛЯНОЙ — җир тутый кошчыгы
ПОПУГАЙЧИК СКАЛЬНЫЙ — кыя тутый кошчыгы
ПОПУГАЙЧИК ТОЛСТОКЛЮВЫЙ — юан томшыклы тутый кошчык



ПОПУГАЙЧИК ТРАВЯНОЙ — үлән тутый кошчыгы
ПОПУГАЙЧИК-ТУИТ — тутый кошчык-туит
ПОПУГАЙЧИК ЭЛЕГАНТНЫЙ (*попугайчик украшенный*) — көяз тутый кошчык
ПОРТНИХА ДЛИННОХВОСТАЯ — озын койрыклы тегәр чыпчык (әрәмәлек чыпчыкларыннан)
ПОЧТОВЫЕ ГОЛУБИ — почта күгәрченнәре
ПРЕДБРАЧНЫЙ НАРЯД — туй алды купшылыгы
ПРЕДСЕРДИЕ — йөрәк алды
ПРОМЫСЛОВЫЕ ПТИЦЫ — аучылык кошлары
ПРОСЯНКА — тары чыпчыгы
ПСЕВДОЗУХИИ — ялган зухилар (кошларның "бабалары")
ПТЕНЕЦ — кош баласы
ПТЕНЦОВЫЕ ПТИЦЫ — җитлегеп бетмәгән бала чыгаручы кошлар (чыпчыксыманнар, күгәрченнәр һ.б.)
ПТЕРИЛИИ — птерилийлар
ПТИЦА-МЫШЬ БЕЛОГОЛОВАЯ — ак башлы тычкан-кош
ПТИЦА-МЫШЬ ДЛИННОХВОСТАЯ — озын койрыклы тычкан-кош
ПТИЦА-МЫШЬ КРАСНОЛИЦАЯ — кызыл яңаклы тычкан-кош
ПТИЦА-МЫШЬ ПОЛОСАТАЯ — буй-буй тычкан-кош
ПТИЦА-СЕКРЕТАРЬ — секретарь (лачынсыманнар отрядыннан ерткыч кош)
ПТИЦЕВОДСТВО — кошчылык
ПТИЦЕЛОВ — кош аулаучы
ПТИЦЕФАБРИКА — кош фабрикасы
ПТИЦЕФЕРМА — кош фермасы
ПТИЦЫ — кошлар
ПТИЦЫ БЕГАЮЩИЕ НАЗЕМНЫЕ — йөгерек кошлар
ПТИЦЫ БРОДНЫЕ (*полуводные*) — сай елга кошлары
ПТИЦЫ ВОДОПЛАВАЮЩИЕ — суда йөзүче кошлар
ПТИЦЫ ВРЕДНЫЕ — зарарлы кошлар
ПТИЦЫ ДНЕВНЫЕ — көндезге кошлар
ПТИЦЫ ЗЕРНОЯДНЫЕ — бөртегашар кошлар
ПТИЦЫ ИСЧЕЗАЮЩИЕ — бетеп баручы кошлар
ПТИЦЫ ИСЧЕЗНУВШИЕ (*вымершие*) — үлеп беткән кошлар
ПТИЦЫ ЛАЗЯЩИЕ КУСТАРНО-ДРЕВЕСНЫЕ — куак-агачларда үрмәләүче кошлар
ПТИЦЫ ЛОВЧИЕ — аулаучы кошлар
ПТИЦЫ-МЫШИ (*мышанки*) — тычкан-кошлар (отряд)
ПТИЦЫ НАЗЕМНЫЕ — җир кошлары

ПТИЦЫ НАСЕКОМОЯДНЫЕ — бөҗәгашар кошлар
ПТИЦЫ-НОСОРОГИ — мөгезборынлы кошлар (күк каргасыманнар отрядыннан)
ПТИЦЫ НОЧНЫЕ — төнге кошлар
ПТИЦЫ ОСЕДЛЫЕ — утрак кошлар
ПТИЦЫ ОХОТНИЧЬИ — сунарчы кошлар, ау кошлары
ПТИЦЫ, ОХОТЯЩИЕСЯ НА ЛЕТУ — очканда аулаучы кошлар
ПТИЦЫ-ПАДАЛЬЩИКИ — үләксәашар кошлар
ПТИЦЫ ПЕВЧИЕ — сайрар кошлар
ПТИЦЫ-ПЕЧНИКИ (*горшечники*) — мичче кошлар, чүлмәкчеләр
ПТИЦЫ ПЛАВАЮЩИЕ — йөзүче кошлар
ПТИЦЫ ПОЛЕЗНЫЕ — файдалы кошлар
ПТИЦЫ РАЙСКИЕ — җәннәт кошлары
ПТИЦЫ РЫБОЯДНЫЕ — балык ашаучы кошлар
ПТИЦЫ РЕДКИЕ — сирәк кошлар
ПТИЦЫ, СКАЧУЩИЕ НАЗЕМНО-КУСТАРНИКОВЫЕ — куаклыкта-җирдә сикергәләп йөрүче кошлар
ПТИЦЫ ТРУПОЯДНЫЕ — үләксәашар кошлар
ПТИЦЫ ХИЩНЫЕ — ерткыч кошлар
ПТИЦЫ ШЕСТВЕННЫЕ НАЗЕМНО-ДРЕВЕСНЫЕ — җирдә-агачта йөрүче кошлар
ПТИЧИЙ БАЗАР — кошлар базары
ПТИЧИЙ ПОМЁТ — кош тизәге
ПУДРЕТКИ — пудреткалар (кошлар корсагында йомшак, тиз сынучан, порошоксыман мамык белән капланган урыннар)
ПУНОЧКА — үлән чыпчыгы
ПУСТЕЛЬГА — торымтай
ПУСТЕЛЬГА АМЕРИКАНСКАЯ — Америка торымтае
ПУСТЕЛЬГА МАВРИКИЙСКАЯ — Маврикий торымтае
ПУСТЕЛЬГА ОБЫКНОВЕННАЯ — төн лачыны, торымтай
ПУСТЕЛЬГА СЕЙШЕЛЬСКАЯ — Сейшель торымтае
ПУСТЕЛЬГА СТЕПНАЯ — дала торымтае
ПУХ — кош мамыгы
ПУХОВЫЕ ПЕРЬЯ — мамык каурыйлар
ПУХОВКА БЕЛОГОРЛАЯ — акбугазлы мамыккош
ПУХОВКА БУРАЯ — коңгырт мамыккош
ПУХОВКОВЫЕ (*ленивковые*) — йомшак каурыйлылар, иренчәкләр (тукрансыманнар отрядыннан)
ПЫЖИК ДЛИННОКЛЮВЫЙ — озын томшыклы пыжик
ПЫЖИК КОРОТКОКЛЮВЫЙ — кыска томшыклы пыжик
ПЫЖИКИ — пыжиклар ( ишкәкканатлылардан)



## Р

РАЗМАХ КРЫЛЬЕВ — канат колачы
РАЙСКИЕ МУХОЛОВКИ — җәннәт чебенчеләре
РАЙСКИЕ ПТИЦЫ — җәннәт кошлары (семьялык)
РАКША КОРОТКОНОГАЯ — кыска аяклы шөлди
РАКШЕОБРАЗНЫЕ — күк каргасыманнар (отряд)
РАМФОТЕКА — томшыкның мөгезләч капламы
РАСПРОСТРАНЕНИЕ ПТИЦ — кошларның таралышы
РАЧЬИ РЖАНКИ — кысла шөлдиләр
РЕМЕЗ (*синица-ремез*) — ремез (песнәк кошлар семьялыгыннан)
РЕЧНЫЕ УТКИ (*благородные утки*) — елга үрдәкләре, затлы үрдәкләр
РЖАНКА — уҗым шөлдие
РЖАНКА ЗОЛОТИСТАЯ — алтын шөлди
РЖАНКОВЫЕ (*куликовые*) — шөлди кошлар (семьялык)
РЖАНКООБРАЗНЫЕ — шөлдисыманнар (отряд)
РОГАТЫЙ ВОРОН — мөгезле козгын
РОГОВОЙ ПОКРОВ КЛЮВА — томшыкның мөгез катлавы
РОГОКЛЮВЫ — мөгез томшыклылар, яссы томшыклылар
РОЗЕЛЛА — розелла (тутый кошлар төре)
РОНЖА — урман каргасы
РЫБНЫЕ ФИЛИНЫ (*рыбные совы*) — балык байгышлары
РЫХЛОЕ ОПЕРЕНИЕ — көпшәк каурыйлар
РЯБИННИК (*дрозд-рябинник*) — миләш чыпчыгы
РЯБКОВЫЕ (*рябки*) — дала күгәрченнәре (семьялык)
РЯБОК БЕЛОБРЮХИЙ — ак корсаклы дала күгәрчене
РЯБОК ЧЕРНОБРЮХИЙ — кара корсаклы дала күгәрчене
РЯБЧИК — боҗыр
РЯБЧИК ВОРОТНИЧКОВЫЙ — якалы боҗыр

## С

САВКА БЕЛОГОЛОВАЯ — ак башлы савка (үрдәк кошлар семьялыгыннан)
САДЖА — саджа, дала күгәрчене
САДЖА ТИБЕТСКАЯ (*горняк*) — Тибет (тау) күгәрчене
САЛАНГАНА СЕРАЯ — соры салангана (керәшә)
САЛАНГАНЫ — саланганалар (керәшә, аерыкойрык ыругы)
САПСАН — сапсан (лачыннар төре)

САРЫЧ ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади елак карчыга
САРЫЧИ (*канюки*) — елак карчыгалар
СВЕРЧКИ — чикерткә чыпчыклар (сайраулары чикерткәгә охшаш)
СВЕРЧОК ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади чикерткә чыпчык
СВЕРЧОК РЕЧНОЙ — елга чикерткә чыпчыгы
СВЕРЧОК СОЛОВЬИНЫЙ — сандугачсыман чикерткә чыпчык
СВИРИСТЕЛИ — сызгырак чыпчыклар
СВИЯЗЬ — кыр үрдәге (төре)
СЕКРЕТАРЬ — секретарь (ерткыч кош)
СЕЛЕЗЕНЬ — ата үрдәк
СЕРАЯ КУРОПАТКА — соры көртлек
СЕРДЦЕВИНА СТВОЛА — каурый көпшәсе үзәге
СЕРИЕМА — сериема
СЕРИЕМОВЫЕ (*кариамовые*) — сериемакошлар, кариамкошлар (торнасыманнар отрядыннан семьялык)
СЕРПОКЛЮВ — урак томшыклы шөлди
СЕРЫЙ ГУСЬ — соры каз
СЕРЫЙ ЖУРАВЛЬ — соры торна
СИЗОВОРОНКА — күк карга
СИЗОВОРОНКА ВИЛОХВОСТАЯ — сәнәк койрыклы күк карга
СИЗОВОРОНКА РАКЕТОХВОСТАЯ — ракета койрыклы күк карга
СИЗОВОРОНКОВЫЕ (*древесные ракши*) — күк каргалар, агач каргалары (семьялык)
СИЗЫЙ ГОЛУБЬ (*сизарь*) — күк күгәрчен
СИНИЦА — песнәк
СИНИЦА БОЛЬШАЯ (*синица-кузнечик*) — зур песнәк
СИНИЦА ДЛИННОХВОСТАЯ (*хвостатая синичка, ополовничек*) — озын койрыклы песнәк
СИНИЦА УСАТАЯ (*бородатка*) — мыеклач песнәк
СИНИЦА ХОХЛАТАЯ (*гренадерка, хохлуша*) — бүрекле песнәк
СИНИЦА ЧЁРНАЯ (*московка, моховушка*) — кара песнәк
СИНИЦЕВЫЕ — песнәк кошлар (семьялык)
СИНИЧКА БЕЛАЯ (*лазоревка белая, князёк*) — ак песнәк
СИНИЧНИК — песнәк оясы
СИНЯЯ ПТИЦА — зәңгәр кош (миләш чыпчыклары семьялыгыннан)
СИП БЕЛОГОЛОВЫЙ — ак башлы сип (грифлардан)
СИПУХА БЕЛАЯ — ак чырылдык ябалак
СИПУХОВЫЕ — чырылдык ябалаклар (семьялык)
СИПЫ — сиплар (грифлар ыругыннан)



СКВОРЕЦ — сыерчык
СКВОРЕЦ ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади сыерчык
СКВОРЕЦ РОЗОВЫЙ — ал сыерчык
СКВОРЕЧНИК — сыерчык оясы
СКВОРЦОВЫЕ — сыерчык кошлар (семьялык)
СКОПА — канмәргән, скопа (лачынсыманнар отрядыннан)
СКОРЛУПА ЯЙЦА — йомырка кабыгы
СЛАВКА-ЗАВИРУШКА (*славка-мельничек*) — алдар чыпчык
СЛАВКА САДОВАЯ (*славка-смородинка*) — бакча чыпчыгы
СЛАВКА СЕРАЯ (*белогорлик, славка-говорунчик*) — соры чыпчык
СЛАВКА ЧЕРНОГОЛОВАЯ (*славка-черноголовка*) — кара башлы чыпчык
СЛАВКА ЯСТРЕБИНАЯ (*славка-пестрогрудка*) — карчыга-чыпчык, чуар түшле чыпчык
СЛАВКОВЫЕ — әрәмә чыпчыклары (семьялык)
СЛОЖНЫЙ КРЕСТЕЦ — оча башы сөяге, катлаулы әвернә сөяге
СНЕГИРЬ — балан чыпчыгы, карабүрек
СОВА — ябалак
СОВА БЕЛАЯ — ак ябалак
СОВА БОЛОТНАЯ — саз ябалагы
СОВА ГОЛОНОГАЯ — шәрә аяклы ябалак
СОВА ИГЛОНОГАЯ — энә аяклы ябалак
СОВА КРОЛИЧЬЯ (*сова норная*) — йорт куяны ябалагы, өн ябалагы
СОВА УШАСТАЯ — зур колаклы ябалак
СОВА ХОХОЧУЩАЯ — шаркылдык ябалак
СОВА ЯСТРЕБИНАЯ — карчыга ябалагы
СОВИНЫЕ — ябалак кошлар (семьялык)
СОВКА ОБЫКНОВЕННАЯ (*сплюшка, зорька*) — гади ябалакчык
СОВКА ОШЕЙНИКОВАЯ — муенчаклы ябалакчык
СОВКА СЕЙШЕЛЬСКАЯ — Сейшель ябалакчыгы
СОВКА УССУРИЙСКАЯ — Уссури ябалакчыгы
СОВКА ФИЛИППИНСКАЯ — Филиппин ябалакчыгы
СОВООБРАЗНЫЕ — ябалаксыманнар (отряд)
СОЙКА — күкшә, урман саесканы, күкканат
СОЙКА САКСАУЛЬНАЯ — саксаул күкшәсе
СОКОЛ — лачын
СОКОЛ НОВОЗЕЛАНДСКИЙ — Яңа Зеландия лачыны
СОКОЛИНАЯ ОХОТА — лачын белән аулау
СОКОЛИНЫЕ — лачын кошлар (семьялык)
СОКОЛООБРАЗНЫЕ — лачынсыманнар (отряд)

СОКОЛ ЭЛЕОНОРЫ — Элеонора лачыны
СОЛОВЕЙ — сандугач
СОЛОВЕЙ ВОСТОЧНЫЙ — көнчыгыш сандугачы
СОЛОВЕЙ ЗАПАДНЫЙ — көнбатыш сандугачы
СОЛОВЬИ — сандугачлар
СОЛОВЬИНЫЙ СВЕРЧОК — сандугачсыман чикерткә чыпчыгы
СОРНЫЕ КУРЫ — чүп тавыклары (күкәйләрен чүп-чар өеменә яки комга күмеп җылыталар)
СОРОКА — саескан
СОРОКА ГОЛУБАЯ — зәңгәр саескан
СОРОКОПУТ БОЛЬШОЙ — зур каракош
СОРОКОПУТ СЕРЫЙ — соры каракош
СОРОКОПУТ ЧЕРНОЛОБЫЙ — кара маңгайлы каракош
СОРОКОПУТОВЫЕ — каракошлар (семьялык)
СОЮЗ ОХРАНЫ ПТИЦ РОССИИ — Россиядә кошларны саклау берлеге
СПИННОЙ МОЗГ — арка мие
СПЛЮШКА (*зорька*) — йокычан ябалакчык
СТАЯ ПТИЦ — кошлар көтүе, кошлар өере
СТВОЛ ПЕРА — каурый сабы, каурый көпшәсе
СТЕНОЛАЗ — дивар үрмәләче
СТЕНОФАГИ — чикләнгән төр азык белән туклану
СТЕРВЯТНИК — үләксә кошы, козгын
СТЕРЖЕНЬ ПЕРА — каурый үзәге
СТЕРХ (*журавль белый*) — ак торна
СТРАУС — тәвә кошы
СТРАУС АФРИКАНСКИЙ — Африка тәвә кошы
СТРАУСОВЫЕ ФЕРМЫ — тәвә кошы үрчетү фермалары
СТРАУСООБРАЗНЫЕ — тәвә кошысыманнар
СТРЕМЕЧКО (*слуховая косточка*) — өзәңге (колак эчендә)
СТРЕПЕТ — сиртмәкойрык
СТРИЖ БЕЛОБРЮХИЙ — ак корсаклы керәшә
СТРИЖ БЕЛОПОЯСНЫЙ — ак билле керәшә
СТРИЖ КАМЕННЫЙ — таш керәшәсе
СТРИЖ ПАЛЬМОВЫЙ — пальма керәшәсе
СТРИЖ УСАТЫЙ — мыеклы керәшә
СТРИЖ ЧЁРНЫЙ — кара керәшә, кара яр карлыгачы
СТРИЖЕОБРАЗНЫЕ (*длиннокрылые*) — керәшәсыманнар, озын канатлылар
СТРИЖИ — керәшәләр
СТРИЖИ ДРЕВЕСНЫЕ (*хохлатые*) — куак керәшәләре
СТРИЖИ ИГЛОХВОСТЫЕ — энә койрыклы керәшәләр



СТРИЖИ ХОХЛАТЫЕ — бүрекле керәшәләр
СУЛТАНКА (*султанская курица*) — солтан тавык (торнасыманнар отрядыннан)
СУХОНОС — корыборын (үрдәкләр төре)
СЫЧ — чырайсыз ябалак
СЫЧ ВОРОБЬИНЫЙ — чыпчык чырайсыз ябалагы
СЫЧ ДОМОВЫЙ — йорт чырайсыз ябалагы
СЫЧ МОХНОНОГИЙ — йөнтәс аяклы ябалак
СЫЧИ — чырайсыз ябалаклар (ябалак кошлар семьялыгыннан вак кошлар)
СЫЧИК-ЭЛЬФ — эльф-ябалакчык

## Т

ТАНАГРОВЫЕ — танагр кошлар (сайрар чыпчыклардан)
ТЕТЕРЕВ — урман тавыгы
ТЕТЕРЕВИНЫЕ — урман тавыклары (семьялык)
ТЕТЕРЕВ КАВКАЗСКИЙ — Кавказ урман тавыгы
ТЕТЕРЕВ СТЕПНОЙ — дала тавыгы
ТЕТЕРЕВЯТНИК (*утятник, большой ястреб*) — тавык карчыгасы
ТИМЕЛИЕВЫЕ — тимелия кошлар (сайрар чыпчыклар семьялыгынан)
ТИНАМУ КАРЛИКОВЫЙ — кәрлә тинаму
ТИНАМУ КРАСНОКРЫЛЫЙ — кызыл канатлы тинаму
ТИНАМУОБРАЗНЫЕ — тинамусыманнар (яшерен койрыклылар)
ТИНАМУ ПЁСТРЫЙ — чуар тинаму
ТИНАМУ РЫЖИЙ — җирән тинаму
ТИНАМУ ХОХЛАТЫЙ — бүрекле тинаму
ТИРАННОВЫЕ — тиранний кошлар (чыпчыксыманнар отрядыннан)
ТИРАННЫ — тираннийлар
ТИРКУШКА ЛУГОВАЯ — болын тиркушкасы
ТИРКУШКА СТЕПНАЯ — дала тиркушкасы (шөлди кошлар семьялыгыннан)
ТИРКУШКОВЫЕ — тиркушка кошлар (шөлдиләрдән)
ТКАЧИ — тукырлар
ТКАЧИКОВЫЕ — тукыр кошлар (семьялык)
ТОДИ КУБИНСКИЙ — Куба тодие (гади күк каргалардан)

ТОДИ УЗКОКЛЮВЫЙ — тар томшыклы тоди
ТОДИ ШИРОКОКЛЮВЫЙ — киң томшыклы тоди
ТОДИЕВЫЕ (*плоскоклювы*) — тоди кошлар, яссы томшыклар
ТОК (*токовище*) — кошларның туй алдыннан уйнау мәйданы
ТОКОВАНИЕ — кошларның туй уеннары
ТОКО ДЕККЕНА (*черноклювый токо*) — Деккен токосы, кара томшыклы токо
ТОКО ЖЕЛТОКЛЮВЫЙ — сары томшыклы токо
ТОКО КРАСНОКЛЮВЫЙ — кызыл томшыклы токо
ТОКО СЕРЫЙ — соры токо
ТОКОВОЙ ПОЛЁТ — туй очышы
ТОЛСТОКЛЮВЫЕ СИНИЦЫ — юан томшыклы песнәкләр
ТОПОРИК — балтачык (ишкәкканатлылардан)
ТРАГОПАНЫ — трагопаннар (кыргавылларның бер ыругы)
ТРЁХПАЛАЯ ЧАЙКА (*моёвка, говорушка*) — өч бармаклы акчарлак
ТРЁХПЕРСТКА ПЯТНИСТАЯ — тимгелле өчбармаклы кош
ТРЁХПЕРСТКОВЫЕ — өчбармаклылар (торнасыманнар отрядыннан)
ТРОГОН КУБИНСКИЙ — Куба трогоны
ТРОГОНООБРАЗНЫЕ — трогонсыманнар (отряд)
ТРОГОНЫ — трогоннар (семьялык)
ТРУБАЧИ (*агами*) — трубачлар (торнасыманнар отрядыннан)
ТРУПИАЛОВЫЕ (*иволги американские*) — трупиал кошлар, Америка шәүләгәннәре
ТРЯСОГУЗКА — чәберчек
ТРЯСОГУЗКА БЕЛАЯ — ак чәберчек
ТРЯСОГУЗКА ГОРНАЯ — тау чәберчеге
ТРЯСОГУЗКА ЖЁЛТАЯ — сары чәберчек
ТРЯСОГУЗКА ЖЕЛТОГОЛОВАЯ — сары башлы чәберчек
ТРЯСОГУЗКА ЖЕЛТОСПИННАЯ — сары аркалы чәберчек
ТРЯСОГУЗКОВЫЕ — чәберчек кошлар (семьялык)
ТУКАНЫ (*перцеядовые*) — тукан кошлар, борычашарлар (туркансыманнар отрядыннан)
ТУЛЕС — тулес (шөлди кошлар семьялыгыннан)
ТУПИК МОРСКОЙ — диңгез тупигы
ТУПИКИ — тупиклар (ишкәкканатлылар семьялыгыннан)
ТУРАКО — турако (кәккүксыманнар отрядыннан)
ТУРАКО БАННЕРМАНА — Баннерман туракосы
ТУРАКО БЕЛОБРЮХИЙ — ак корсаклы турако



ТУРАКО ХОХЛАТЫЙ — бүрекле турако
ТУРАКО ЭФИОПСКИЙ — эфиоп туракосы
ТУРАЧ (*франколин*) — турач, франколин (кыргавыл)
ТУРУХТАН — корыхтан (шөлди кошлар семьялыгыннан)

## У

УДОД — һөдһөд
УДОДОВЫЕ — һөдһөдсыманнар (отряд)
УДОДЫ ДРЕВЕСНЫЕ — агач һөдһөдләре
УДОД СЕРПОВИДНЫЙ (*удод черноспинный*) — ураксыман һөдһөд, кара аркалы һөдһөд
УЗДЕЧКА ЯЗЫКА — тел тезгене
УЛАР (*горная индейка*) — улар, тау күркәсе
УЛАР АЛТАЙСКИЙ — Алтай күркәсе
УЛАР ГИМАЛАЙСКИЙ — Һималай күркәсе
УЛАР КАВКАЗСКИЙ — Кавказ таулары күркәсе
УЛАР КАСПИЙСКИЙ — Каспий күркәсе
УЛАР ТИБЕТСКИЙ — Тибет күркәсе
УЛИТ БОЛЬШОЙ — зур улит (шөлди кошлар семьялыгыннан)
УЛИТЫ — улитлар (шөлдиләр ыругы)
УТЁНОК — үрдәк бәбкәсе
УТИНЫЕ — үрдәк кошлар (семьялык)
УТКА — үрдәк
УТКА ДОМАШНЯЯ — йорт үрдәге
УТКА КАРОЛИНСКАЯ — Каролина үрдәге
УТКА КРАСНАЯ — кызыл үрдәк
УТКА-НЫРОК — чүрәкәй үрдәк
УТКА ПЕКИНСКАЯ — Пекин үрдәге
УТКА СЕРАЯ (*серуха*) — соры үрдәк
УТКИ ДРЕВЕСНЫЕ — агач үрдәкләре
УШАСТАЯ СОВА — зур колаклы ябалак
“УШКИ” СОВ — ябалаклар “колакчыгы”

## Ф

ФАБРИЦИЕВА СУМКА — Фабриций сумкасы (кошлар клоакасының арткы өлешендә капчыксыман чыгынты)
ФАЗАН — кыргавыл

ФАЗАН АЛМАЗНЫЙ — алмаз кыргавыл
ФАЗАН ЗОЛОТОЙ — алтын кыргавыл
ФАЗАН КОРОЛЕВСКИЙ — затлы кыргавыл
ФАЗАН ОБЫКНОВЕННЫЙ — гади кыргавыл
ФАЗАН ОХОТНИЧИЙ — сунарчы кыргавыл
ФАЗАН СЕРЕБРИСТЫЙ — көмеш кыргавыл
ФАЗАН УШАСТЫЙ — зур колаклы кыргавыл
ФАЗАНОВЫЕ — кыргавыл кошлар (семьялык)
ФАЛАНГА ПАЛЬЦЕВ — бармаклар буыны
ФАЭТОНОВЫЕ — фаэтон кошлар (диңгез пеликансыманнарыннан)
ФИЛИН АМЕРИКАНСКИЙ — Америка байгышы
ФИЛИН ОБЫКНОВЕННЫЙ — байгыш, мәче башлы ябалак
ФИЛИН РЫБНЫЙ — балык байгышы
ФИЛИНЫ — байгышлар (ябалак кошлар семьялыгының бер ыругы)
ФИЛИППИНСКАЯ ГАРПИЯ (*обезьяноед*) — Филиппин бөркете, Филиппин гарпиясе, маймылашар
ФИЛОГЕНИЯ — филогения (берәр систематик группа организмнарының тарихи үсеш процессы)
ФИТОФАГИ — үсемлегашар кошлар
ФИФИ — фифи (уҗым шөлдиләреннән)
ФЛАМИНГО (*краснокрыл*) — фламинго (кызылканат)
ФЛАМИНГО КРАСНЫЙ (*карибский*) — кызыл фламинго
ФЛАМИНГО РОЗОВЫЙ — алсу фламинго
ФЛАМИНГО ЧИЛИЙСКИЙ — Чили фламингосы
ФЛАМИНГОВЫЕ — фламинго кошлар (семьялык)
ФЛОРИКАН — флорикан (дудәк, дала күркәсе).
ФРЕГАТ БОЛЬШОЙ — зур фрегат (ишкәгаяклылар отрядыннан)
ФРЕГАТОВЫЕ — фрегат кошлар (семьялык)

## Х

ХАЛЗАН (*беркут*) — халзан, бөркет
ХИМАХИМА (*крикливая каракара*) — химахима, ачы тавышлы каракара
ХИМУС — химус
ХИЩНЫЕ ПТИЦЫ — ерткыч кошлар
ХОДУЛОЧНИК — озын аяклы челән
ХОХЛАТЫЕ СТРИЖИ — бүрекле керәшәләр



ХОХЛАТЫЙ ТОККО — бүрекле токко (тавыклар төре)
ХОХОЛОК — бүрек (кошларда)
ХОХОТУН ЧЕРНОГОЛОВЫЙ — кара башлы шаркылдык акчарлак
ХРЯЩ ПЕРСТНЕВИДНЫЙ — балдаксыман кимерчәк

## Ц

ЦАПЛЕВЫЕ — челән кошлар (семьялык)
ЦАПЛИ БЕЛЫЕ — ак челәннәр
ЦАПЛИ СОЛНЕЧНЫЕ — кояш челәннәре
ЦАПЛЯ БЕЛАЯ БОЛЬШАЯ — зур ак челән
ЦАПЛЯ БЕЛАЯ МАЛАЯ — кечкенә ак челән
ЦАПЛЯ ЕГИПЕТСКАЯ — мисыр челәне
ЦАПЛЯ РЫЖАЯ — җирән челән
ЦАПЛЯ СЕРАЯ — соры челән
ЦВЕТНЫЕ БЕКАСЫ — бизәкле чуллыклар
ЦВЕТОЕДОВЫЕ — чәчәгашар кошлар (сайрар чыпчыксыманнардан)
ЦЕВКА — цевка (кошларның арткы очлыкларындагы сегмент)
ЦЕРАТОГИМНА ЧЁРНАЯ (*пальмовая*) — кара цератогимна, пальма цератогимнасы
ЦЕСАРКА ОБЫКНОВЕННАЯ — гади мисыр тавыгы
ЦЫПЛЁНОК — чебеш, чеби

## Ч

ЧАЙКА — акчарлак
ЧАЙКА БЕЛАЯ — ак канатлы акчарлак
ЧАЙКА БОЛЬШАЯ МОРСКАЯ — зур диңгез акчарлагы
ЧАЙКА ВИЛОХВОСТАЯ — сәнәк койрыклы акчарлак
ЧАЙКА ЛАСТОЧКОХВОСТАЯ — карлыгач койрыклы акчарлак
ЧАЙКА МАГЕЛЛАНОВА — Магеллан акчарлагы
ЧАЙКА МАЛАЯ — кечкенә акчарлак
ЧАЙКА МОРСКАЯ — диңгез акчарлагы
ЧАЙКА ОЗЁРНАЯ — күл (елга) акчарлагы
ЧАЙКА ПОЛЯРНАЯ — котып акчарлагы
ЧАЙКА РЕЛИКТОВАЯ — борынгы акчарлак

ЧАЙКА РОЗОВАЯ — ал акчарлак
ЧАЙКА СЕРЕБРИСТАЯ — көмеш акчарлак
ЧАЙКА СИЗАЯ — күк акчарлак
ЧАЙКА СРЕДИЗЕМНОМОРСКАЯ (*черноголовая*) — Урта диңгез акчарлагы, кара башлы акчарлак
ЧАЙКА ТОНКОКЛЮВАЯ (*морской голубок*) — нәзек томшыклы акчарлак, диңгез күгәрчене
ЧАЙКОВЫЕ — акчарлак кошлар (семьялык)
ЧАСТИЧНАЯ ЛИНЬКА — өлешчә каурый алмаштыру
ЧЕГЛОК — чеглок (лачын төре)
ЧЕГЛОК АВСТРАЛИЙСКИЙ — Австралия карчыгасы
ЧЕГЛОК АФРИКАНСКИЙ — Африка карчыгасы
ЧЕГРАВА — чеграва (вак акчарлакларның зуррак төре)
ЧЕКАН ЛУГОВОЙ — болын купшысы (дроздлардан)
ЧЕКАН ЧЕРНОГОЛОВЫЙ — кара башлы купшы
ЧЕЛНОКЛЮВ — көймәтомшык (миләш чыпчыкларыннан)
ЧЕРНЕТИ — кара чумгалак үрдәкләр
ЧЕРНЕТЬ КРАСНОГОЛОВАЯ — кызыл башлы карагай үрдәк
ЧЕРНЕТЬ МОРСКАЯ — диңгез карагае
ЧЕРНЕТЬ ХОХЛАТАЯ — бүрекле карагай
ЧЕРНОЗОБИК — каратүш (шөлди кошлар семьялыгыннан)
ЧЕРНУШКА — кара үрдәк
ЧЕРНЫШ — кара шөлди
ЧЕТВЕРОКРЫЛ — дүрtканат (төн күгәрченнәреннән)
ЧЕЧЕВИЦА АРЧОВАЯ — арча ясмык чыпчыгы
ЧЕЧЕВИЦА ОБЫКНОВЕННАЯ — гади ясмык чыпчыгы
ЧЕЧЕВИЦА СИБИРСКАЯ — себер ясмык чыпчыгы
ЧЕЧЁТКИ — чи-чи чыпчыклар
ЧИБИС (*пигалица*) — тәкәрлек, бибек
ЧИБИС ИНДИЙСКИЙ УКРАШЕННЫЙ — бизәкле һинд тәкәрлеге
ЧИЖ — сары чыпчык
ЧИРКИ — чүрәкәйләр (елга үрдәкләре ыругының вак төрләре)
ЧИРОК-КЛОКТУН — ярсу чүрәкәй
ЧИРОК МРАМОРНЫЙ — мәрмәр чүрәкәй
ЧИРОК-СВИСТУНОК (*грязовик*) — алмабаш, сыбызгы чүрәкәй
ЧИРОК-ТРЕСКУНОК — чытырдавык чүрәкәй
ЧИСТИКИ — ишкәкканатлылар
ЧИСТИКОВЫЕ — ишкәкканатлы кошлар (шөлдисыманнарның бер семьялыгы)
ЧОМГА (*большая поганка*) — зур чомга (үрдәк төре)



## Ш

ШАЛАШНИКИ (*беседковые птицы*) — шалаш, чатыр кошлары (сайрар чыпчыклар)
ШАХИН (*рыжеголовый сокол*) — җирән башлы лачын
ШЕРЕНГА ГУСЕЙ — казлар сафы
ШИЛОКЛЮВКА — безтомшык (ужым шөлдиләреннән)
ШИЛОКЛЮВЫЕ — безтомшыклылар
ШИЛОХВОСТКА — безкойрык (үрдәк төре)
ШИРОКОКЛЮВЫЕ — киң томшыклылар (чыпчыксыманнар отрядыннан)
ШИРОКОНОСКА — киң борынлач (үрдәкләр төре)
ШИРОКОРОТ ВОСТОЧНЫЙ — киң авызлы көнчыгыш күк каргасы
ШИРОКОРОТЫ — киңавызлылар (күк каргалар ыругыннан)
ШЛЕМОНОСНЫЙ НОСОРОГ — шлемлы (якалы) мөгезборын
ШПОРЦЕВЫЙ ГУСЬ — шпорлы каз
ШПОРЫ — шпорлар

## Щ

ЩЕГОЛ — купшыл, купшы чыпчык
ЩУР — корташар кош (тау чыпчыкларыннан)
ЩУРКА ЗЕЛЁНАЯ — яшел карга (күк каргалар семьялыгыннан)
ЩУРКА ЗОЛОТИСТАЯ — алтын карга, сары карга (бал кортларын ашаучы кош)
ЩУРКА КРАСНАЯ — кызыл карга
ЩУРКА ЛАСТОЧКОХВОСТАЯ — карлыгач койрыклы карга

## Э

ЭМБРИОНАЛЬНЫЙ ПУХ — яралгы мамыгы
ЭМУ — эму, Австралия тәвә кошы
ЭНАЛИОРНИС — эналиорнис (акбур чоры кошы)
ЭНТОМОФАГИ — бөҗәгашар кошлар
ЭПИОРНИСООБРАЗНЫЕ — эпиорниссыманнар (үлеп беткән яңа аңкаулы кошлар)
ЭПИТЕКА — томшык өсте

Ю

ЮЛА (*лесной жаворонок*) — урман тургае
ЮРОК (*вьюрок*) — тау чыпчыгы

Я

ЯБИРУ — ябиру (ләкләкләр төре)
ЯГНЯТНИК (*бородач*) — бәрән бөркете, бәрәнче
ЯИЧНИК — күкәйлек
ЯИЧНЫЙ БЕЛОК — йомырка аксымы
ЯЙЦЕВОД — күкәй юлы
ЯЙЦО ПТИЧЬЕ — кош күкәе
ЯКАМАРА ЗЕЛЁНАЯ — яшел якамара (тукрансыманнар отрядыннан)
ЯКАМАРА РЫЖЕХВОСТАЯ — җирән койрыклы якамара
ЯКАМАРА ШИРОКОРОТАЯ — киң авызлы якамара
ЯКАМАРОВЫЕ (*блестянковые*) — ялтыравык чыпчыклар (семьялык)
ЯКАНА АВСТРАЛИЙСКАЯ — Австралия яканасы (уҗым шөлдиләреннән)
ЯКАНА АФРИКАНСКАЯ — Африка яканасы
ЯКАНА ИНДИЙСКАЯ (*якана бронзовокрылая*) — бронза канатлы һинд яканасы
ЯКАНА ФАЗАНОХВОСТАЯ (*водяной фазанчик*) — кыргавыл койрыклы якана, су кыргавылчыгы
ЯКАНЫ — яканнар
ЯСТРЕБ-ПЕРЕПЕЛЯТНИК (*малый ястреб*) — бүдәнә карчыгасы
ЯСТРЕБ-ТЕТЕРЕВЯТНИК — тавык карчыгасы
ЯСТРЕБ-ТЮВИК — тювик карчыга
ЯСТРЕБИНАЯ СОВА — карчыгасыман ябалак
ЯСТРЕБИНЫЕ — карчыга кошлар (семьялык)
ЯСТРЕБИНЫЙ КАНЮК — карчыгасыман елак сарыч
ЯЩЕРОХВОСТЫЕ — кәлтә кошлар

## *КӨРТЛЕК-СУЕР ҖИРДӘ ОЯ ТИБӘ, САНДУГАЧЛАР ТАЛДА МОҢ СИБӘ*

Җәй килде исә туган як кырларында, болыннары, елгакүлләре һәм урманнарында нинди генә кошларны очратмыйсың. Галимнәр исәпләвенчә һәм күзәтүенчә, Татарстан территориясендә җәен канатлы дусларның өч йөзгә якын төре яши икән. Ә элекке Союзда ул 800 төр исәпләнгән. Тагын бер сан китерәсе килә: безнең республикада утрак рәвештә яшәүче алмышлап төр кош барлыгы да билгеле. Аларга төрчәләрен дә кертсәк, бу сан күпкә артачак.

Һәр тереклек, шул исәптән кошлар да Җир йөзенең теге яки бу өлкәләре, районнарының табигать шартларына яраклашканнар. Билгеле, алар арасында утраклыкны вакытлыча алыштыручылары да аз түгел. Шундыйларга күчмә кошлар керә. Ә менә ала карга, саескан, чыпчык, песнәк һ.б. утраклар.

Без, гадәттә, әлеге кошларга шулкадәр ияләшкәнбез, аларның барлыгын да күрмибез. Чөнки алар һәрчак безнең янда — авылда, каралты-кура тирәсендә. Табигатьне, кошларны өйрәним, белим дисәң, "эш"не шулардан башларга кирәк. Сез, саескан белән ала карганың нәрсәсен өйрәнәсең, алардан кем файда күргән, саескан — йомырка карагы, диярсез. Бу — ялгыш фикер. Мин әйтер идем: алар кешедән читләшмиләр, үзләренә күрә акыллы һәм зирәкләр дә.

Бер кышны авылда ала карганы берничә көн күзәттем. Әлеге кош иртәсен бакча коймасына килә дә куна. Күзләрен болдыр ишегенә төби. Янәсе, өйдән берәрсе ризык калдыклары чыгарып ташламасмы? Шатлыгыннанмы, карга кунаклаган урынында канатларын кагып куя, биегәндәй аякларын күтәргәли. Бу җан иясе тагын нишләр икән, — дип, болдыр эченә керәм, аны тәрәзәдән күзәтәм. Калдык ашамлык кисәкләрен элəктереп, "кунак" бәрәңге бакчасы ызанына барып төште, аннары табышын кибеп каткан алабута сабагы төбенә, карга яшерде. Кош берничә мәртәбә шундый очыш ясады, аннары койма төбендә калган ризык калдыкларын урында ашарга кереште. Менә син аны зирәк түгел, диген инде. Ул алдагы көннәргә үзенә азык запасы ясады. Үрмәләч, тукран, башка кайбер кошларның да кышка азык туплау гадәте бар.

Саескан да алардан калышмый икән. Җитмәсә, ул кешедән дә әлләни курыкмый, әрсезлеге дә җитәрлек. Шулай дигәннән, безнең бакчаларны үз итте бит саесканнар. Шундагы алмагач, миләш агачларында оя коралар, бала чыгаралар. Нәниләрен үстереп, алар белән бергә көннәр буе "чыкыр-чыкыр" килеп йөриләр. Саесканнар да — файдалы кошлар. Алар урманда һәм бакчаларда көзен коелган яфраклар астында яшеренеп яткан каты кортларны һ.б. бөҗәкләрне юк итәләр.

Бакчада ала яки кара карга күренсә, алар, бергә җыелып, "чакырылмаган кунак"ларны үз биләмәләреннән дәррәү куып чыгаралар.

Мин шундый хәлнең дә шаһиты булдым. Бакчамда мари урманнарыннан төпләп алып кайткан чыршы һәм нарат үсеп утыра. Хәзер алар, биек үсеп, киңәеп киттеләр. Бер язны пар ала карга наратта оя кора башлады. Ояларын бетереп кенә килгән көннәрнең берендә саесканнар каргаларга һөҗүмгә күчтеләр. Түзеп кенә тор ! Һөҗүм көчле булды. Пар ала карга түзмәде, каядыр очып киттеләр. Саесканнар ояларын пыран-заран китереп туздырдылар, чыбык-чабыкны каядыр ерак илтеп ташладылар. Әнә ничек тә була икән әле: чит биләмәгә тыгылсаң, хуҗалары сине тиз куып чыгаралар.

Биредә күкшә, миләш чыпчыгы кебек кошларга да урын юк. Саесканнар аларга яу кебек ташлана. Янәсе, сезнең яши торган җирегез — урман кочагы.

Моннан ун еллар чамасы элек безнең бакчачыларның әрсез бер саесканы бар иде. Ашыйсы килсә, ул ишек төбендә өйдән хуҗа чыкканны көтеп утыра, сыйланмыйча беркая да китми иде. Аның гадәте йорт саен "теләнеп" йөрү иде. Без үзебез дә яраттык ул кошны. Ишек янында кайчан күренер икән? — дип, көтә идек аны. Кош булса да, саесқан безнең мәрхәмәтлелекне бик яхшы аңлый иде.

Уйлап карасаң, кошлар кеше ярдәменә бик мохтаҗ. Әйе, җәен аларга яшәве җиңел — туклану өчен азык җитәрлек. Ә кышын? Елның бу фасылын канатлы дусларыбыз авыр кичерә, ачлыктан күпләп һәлак булалар. Бигрәк тә песнәкләр. Кышның җепшек көннәрендә агач ботаклары боз элпәсе белән каплана. Ә анда песнәкләр өчен күпме азык — ярыкларда кечкенә бөҗәкләр, корткыч кортларның курчаклары, йомыркалары яшеренгән була. Шуңа күрә песнәкләр һәм башка кошчыклар кышын авылга юнәләләр, каралты-кура тирәсенә елышалар.

Ярдәмгә килегез сез, балалар, кышын ачлыктан интегеп очып йөрүче кошларга! Алар өчен туклану җайланмалары булдырыгыз.



Уткойрык һәм песнәк — урман кошлары. Әмма алар бакчада да яшиләр. Яшиләр генә түгел, шунда оя коралар, бала чыгарып үстерәләр. Алар җәй буе җимеш агачларыннан корткыч бөҗәкләрне тотып ашыйлар. Шуның белән зур файда китерәләр.

Канатлы дусларның төрләре бик күп, дидек. Аларның берәүләре — урманда, икенчеләре — болын-кырларда, өченчеләре сулыкларда яшәү һәм үрчү өчен яраклашкан. Ә менә урман тавыгы, сандугачлар беренче җырларын сузганда, җирдә оя тибә, йомырка сала.

Мин бу җан иясен бик яхшы беләм. Малай чакта аның чебешләрен тотып, читлектә асрап караганым да бар. Бик терчә алар. Тик шунысы уңайсыз булды: мин аларга нәрсә ашатасын белми идем. Алларына ипи валчыклары, төрле ярма, вак чебен, хәтта җансыз кырмыскалар да сала идем. Ни хикмәт, алларында азык шул килеш кала иде. Озын сүзнең кыскасы, чебиләрем, тишек табып, читлектән чыгып качтылар. Мин бу шөгыльдән кул селектем. Нәниләрне тоткынлыкта нигә газапларга? Яши бирсеннәр үзләренең урманнарында.

Билгеле, аларны тотуы җиңел эш түгел. Алар, күз ачып йомганчы, үлән арасына, агач куелыгына керәп качалар. Ә аналары, канаты каерылган кош кебек, уңга-сулга ава-түнә сине үз артыннан ияртә. Янәсе, мин яралы, мине тот. Алданып аның артыннан йөгергәндә, чебешләрдән җил искән була. Ана көртлекнең бу хәйләкәрлегенә тиз төшендем, балалары артыннан чабып, аларны әләктерә идем. Үсә төшкәч, шуны аңладым: кошларны һич тә кыерсытырга ярамый. Минутлык, сәгатьлек шуклыкка бирелеп, кош язмышы белән уйнау яхшы "һөнәр" түгел. Шулаен-шулай да, табигать сөючеләр, натуралистлар арасында суерларны (урман күркәләрен) кулга ияләштерүчеләр, аларны вольерларда асраучылар да бар. Әйтик, Мәскәү читендә яшәүче берәү егермеләп суер тота. Бу кошлар, урманда яшеренеп яшәсәләр, кеше күзенә күренмәскә тырышсалар да, вольерда үзләрен әйбәт хис итәләр. Хуҗалары алардан үрчем алырга да җыена.

Минемчә, безнең республика табигате шартларында кашкалакны да (су тавыгы) кулга ияләштерергә һәм асрарга мөмкин. Ул һәм аның бер төрчәсе булган камыш тавыгы җәйге чорны безнең як күлләрендә һәм сазлыкларында да кичерәләр. Аларны Казанның камышлы күлләрендә дә очратырга була. Мәсәлән, камыш тавыклары безнең йорт каршындагы күлчектә яздан алып октябрь аена кадәр яшиләр, җәен яшь токым үстерәләр. Мин аларны бинокльдән һәркөн диярлек күзәтәм. Билгеле, алар кешегә күренмәскә тырышалар. Биек

камышлар арасыннан чыгып, күл өстен каплаган мөгезь-яфрак, бака тәңкәсе, камыш һ.б. белән туклананалар. Ә кыр үрдәкләренең кешеләргә исләре дә китми. Якын-тирәдә яшәүче кешеләр аларны ипи белән сыйлыйлар. Гомумән Казан күлләрендә кыр үрдәкләре бик күп.

Кашкалак һәм камыш тавыгы зурлыклары белән уртача кошлардан санала. Төсләре кара, кыска койрыклы һәм озын аяклылар. Гәүдәләренең ян-ягыннан тасма сыман аксыл-соры төстәге бизәк сузыла. Алар йөзәләр дә, үрдәк кебек чумалар да.

Безнең урманнарда яшәүче кошлар арасында матурлары да хәтсез. Утрак купшыл да — шундыйларның берсе. Чыпчык кадәрле бу кошчыкка юкка гына шундый исем бирмәгәннәр. Табигать аңа күзләрне камаштырырлык төс-бизәкләр биргән. Безнең якның җәйге кунагы шәүлегән (яңгыр теләнчесе) — алтын-сары, кыштума яшькелт-зәңгәр "күлмәк"ләре белән кешене сокландырсалар, купшыл исә маңгае һәм тамак асты карасу-кызыл, муены кара һәм ак, аркасы һәм түше кызгылт-көрән, канатлары сары, каралы-аклы төсләре белән һәркемне үзенә җәлеп итә. Шул чибәрлекләре аркасында, алар шәһәр малайлары читлекләренә дә эләгәләр.

Купшыллар туклану ягыннан талымсызлар — урманда агач, кырда тигәнәк, алабута орлыклары белән тамак ялгыйлар. Алар үзләренчә җырлаган да булалар.

Кыштуманы башка кошчыклар белән бутавы кыен. Аның биләмәсе — инеш, кечкенә елгалар. Ул, ярда оялап бала чыгарса да, көннәре суда маймычлар аулап уза, су төбендәге бөҗәкләрне тота. Кыштума — су кошчыгы. Шул тирәлеккә яраклашкан ул. Томшыгы зур һәм без кебек очлы, койрыгы бик кыска, аяклары кыска һәм таза. Бу кош кышкы салкыннардан да курыкмый. Елга-инешнең боз белән капланмаган урыннарында сай суга чумып, су астыннан йөгереп, үзенә азык таба. Аксыл-сары түшле, коңгырт-карасу төсләргә манчылган су чыпчыгы да, кыштума кебек, елга-инеш буйларында яши, судагы тереклек белән туклана.

Татарстан территориясендә күп төрле кошлар яши. Бу исә республикабызның табигать шартларының уңайлы булуы белән аңлатыла. Шуңа күрә бездә утырма, күчмә канатлы дуслар төре дә күп. Язын безнең як аша Төньякка, Себер тайгаларына үтүче кошлар да безнең урманнарда һәм сулыкларда тукталыш ясыйлар, сәфәрләрен дәвам иттерү өчен көч туплыйлар.

**КАСЫЙМ ТӘХАУ**

## Кошлар

### А

АВСТРАЛИЯ АККҮЗ ЧЫПЧЫГЫ — белоглазка австралийская
АВСТРАЛИЯ ИЛГИЗӘРЛӘРЕ — австралийские странники
АВСТРАЛИЯ КАРЧЫГАСЫ — чеглок австралийский
АВСТРАЛИЯ ТОРНАСЫ — журавль австралийский
АВСТРАЛИЯ ЯКАНАСЫ (*уҗым шөлдиләреннән*) — якана австралийская
АВЫЛ КАРЛЫГАЧЫ — ласточка деревенская, касатка
АГАЧ КАРГАЛАРЫ (*күк каргалар*) — сизоворонковые, древесные ракши
АГАЧ КЕРӘШӘЛӘРЕ — стрижи древесные
АГАЧ КОШЛАРЫ — древесницевые
АГАЧ КУЫШЫНДА ОЯЛАУЧЫЛАР — дуплогнёздники
АГАЧ КУЫШЫНДАГЫ ОЯ — дуплянка
АГАЧ ТАВЫКЛАРЫ (*гокко, кракслар*) — древесные куры , гокко, краксы
АГАЧ ҮРДӘКЛӘРЕ — утки древесные
АГАЧ ЧЫПЧЫКЛАРЫ — вьюрки древесные
АГАЧ ҺӨДҺӨДЛӘРЕ — удоды древесные
АГАЯК (*миләш чыпчыкларыннан*) — белоножка
АДЕЛЬ ПИНГВИНЫ — пингвин Адели
АЕРЧА КОЙРЫКЛЫ ТИЛГӘН — коршун вилохвостый
АЕРЫЛМАС ТУТЫЙ КОШЛАР — неразлучники
АК АКЧАРЛАК — крачка белая
АК АРКАЛЫ ДАВЫЛ КОШЫ — альбатрос белоспинный
АК АРКАЛЫ ТУКРАН — дятел белоспинный
АК БАШЛЫ ДИҢГЕЗ БӨРКЕТЕ — орлан белоголовый
АК БАШЛЫ САВКА (*үрдәкләрдән*) — савка белоголовая
АК БАШЛЫ СИП (*грифлардан*) — сип белоголовый
АК БАШЛЫ ТАШ ЧЫПЧЫГЫ — каменка-плешанка
АК БАШЛЫ ТЫЧКАН-КОШ — птица-мышь белоголовая
АК БИЛЛЕ КЕРӘШӘ — стриж белопоясный
АК БУГАЗЛЫ МАМЫККОШ — пуховка белогорлая
АК БҮРЕКЛЕ СОЛЫ ЧЫПЧЫГЫ — овсянка белошапочная

**АК ДРОНТ** (*бурбон дронты*) — дронт белый, дронт бурбонский
**АК ИҢСӘЛЕ ДИҢГЕЗ БӨРКЕТЕ** — орлан белоплечий
**АК КАНАТЛЫ АКЧАРЛАК** — крачка белокрылая
**АК КАНАТЛЫ КУГЫЧ** — погоныш белокрылый
**АК КАНАТЛЫ ТУРГАЙ** — жаворонок белокрылый
**АК КАНАТЛЫ ЧУКЫР** — клёст белокрылый
**АК КАШЛЫ САЙРАР САНДУГАЧ** — дрозд белобровик
**АККОЙРЫК** — белохвост
**АК КОЙРЫКЛЫ ДИҢГЕЗ БӨРКЕТЕ** — орлан-белохвост
**АК КОЙРЫКЛЫ КОМ ШӨЛДИЕ** — песочник белохвостый
**АК КОЛАКЛЫ КАРА КАКАДУ** — какаду белоухий чёрный
**АККОРСАК** — белобрюшка
**АК КОРСАКЛЫ ДАЛА КҮГӘРЧЕНЕ** — рябок белобрюхий
**АК КОРСАКЛЫ КЕРӘШӘ** — стриж белобрюхий
**АК КОРСАКЛЫ ТУРАКО** — турако белобрюхий
**АККОШ** — лебедь
**АК КӨРТЛЕК** — куропатка белая
**АККҮЗ КОШЛАР** (*сайрар чыпчыклардан*) — белоглазковые
**АК КҮЗЛЕ ЧУМГАЛАК** — нырок белоглазый
**АК ЛАЧЫН** (*аучылык кошы*) — кречет белый
**АК ЛӘКЛӘК** — аист белый
**АК МАҢГАЙЛЫ КАЗ** — гусь белолобый
**АК МАҢГАЙЛЫ КАЗАРКА** — казарка белолобая
**АКМУЕН** — белошейка
**АК МУЕНЛЫ ДРОЗД** — дрозд белогорлый
**АК МУЕНЛЫ КАЗ** — белошей
**АК МУЕНЛЫ САКАЛТӘЙ** (*тукрансыманнардан*) — бородатка белошеяя
**АК МУЕНЛЫ ЧЕБЕНЧЕ** — мухоловка-белошейка
**АК ПЕСНӘК** — лазоревка белая
**АК ТОМШЫКЛЫ ТУКРАН** — дятел белоклювый
**АК ТОРНА** — журавль белый, стерх
**АК ТУКРАН** — дятел белый
**АК УҖЫМ ШӨЛДИЛӘРЕ** — ржанки белые
**АКЧАРЛАК** — чайка
**АКЧАРЛАК КОШЛАР** (*семьялык*) — чайковые
**АК ЧЕЛӘННӘР** — цапли белые
**АК ЧЫРЫЛДАВЫК** (*ябалаксыманнардан*) — сипуха белая
**АК ЧӘВЕРЧЕК** — трясогузка белая
**АК ЯБАЛАК** — сова белая
**АК ЯҢАКЛЫ АКЧАРЛАК** — крачка белощёкая



**АК ЯҢАКЛЫ БАНАНАШАР** — бананоед белощёкий
**АК ЯҢАКЛЫ ВЫЛБЫЛ** — бюльбюль белощёкий
**АК ЯҢАКЛЫ КАЗАРКА** — казарка белощёкая
**АЛ АКЧАРЛАК** — чайка розовая
**АЛА КАРГА** — ворона серая
**АЛА-КОЛА ЗУР ЯР ЧЫПЧЫГЫ** — зимородок большой пегий
**АЛА ТУКРАН** — дятел седой
**АЛА ЧУМГАЛАК** (*үрдәкләр ыругыннан*) — гоголь
**АЛДАР ЧЫПЧЫК** — славка-завирушка
**АЛЕУТ АКЧАРЛАГЫ** — крачка алеутская
**АЛКАЛЫ УРМАН КҮГӘРЧЕНЕ** — горлица кольчатая
**АЛМАБАШ** (*сыбызгы чүрәкәй*) — чирок-свистунок
**АЛМАЗ КЫРГАВЫЛ** — фазан алмазный
**АЛСУ БАБАКОШ** — пеликан розовый
**АЛСУ КАКАДУ** — какаду розовый
**АЛСУ КҮГӘРЧЕН** — голубь розовый
**АЛСУ ФЛАМИНГО** — фламинго розовый
**АЛ СЫЕРЧЫК** — скворец розовый
**АЛТАЙ КҮРКӘСЕ** — улар алтайский
**АЛТЫН КАРГА** (*сары карга*) — щурка золотистая
**АЛТЫН КЫРГАВЫЛ** — фазан золотой
**АЛТЫНСЫМАН АРАТИНГА** — аратинга золотистый
**АЛТЫН ТУКРАННАР** — дятлы золотые
**АЛТЫН ШӨЛДИ** — ржанка золотистая
**АЛЫП ДАВЫЛ КОШЫ** — буревестник гигантский
**АЛЫП ЧЕБЕНКОШ** — колибри исполинский
**АЛЬБАТРОС** — давыл кошы
**АЛЬП ТАВЫ ЧӘҮКӘСЕ** — галка альпийская
**АМАЗОН ТУТЫЙ КОШЛАРЫ** — попугаи амазонские
**АМЕРИКА БАЙГЫШЫ** — филин американский
**АМЕРИКА ГРИФЛАРЫ** — американские грифы
**АМЕРИКА ТОРЫМТАЕ** (*төн лачыны*) — пустельга американская
**АМЕРИКА ТӘПИЧӘ АЯГЫ** — лапчатоног американский
**АМЕРИКА ӘРӘМӘ ЧЫПЧЫКЛАРЫ** (*урман сайрар кошлары*) — американские славковые (лесные певуны)
**АМУР ЯГЫЛБАЕ** — кобчик амурский
**АНА КАЗ** — гусыня
**АНА КҮГӘРЧЕН** — голубка
**АНА КҮРКӘ** — индейка, индюшка
**АНА КҮРКӘ-ГРИФ** — гриф-индейка
**АНАЛЫК ҖИҢСӘСЕ** — влагалище

АНИ КҮКЕСЕ — кукушка ани
АНТИГОНА (*һинд торнасы*) — антигона, журавль индийский
АОРТАНЫҢ (*сул як*) ВЕНА ДУГАСЫ — веночная дуга аорты
АПТЕРИЙЛАР (*кош тиресендә каурыйсыз ялангач урыннар*) — аптерии
АРА ТУТЫЙ КОШЛАРЫ — попугаи ара
АРАМИЛАР (*сазлык көтүчеләре; торнасыманнардан*) — арамовые журавли, пастушковые журавли
АРАРА (*чын ара*) — арара
АРАРАУНА (*тутый кошлардан*) — арараунa
АРГУСЛАР (*кыргавыллардан*) — аргусы
АРКА МИЕ — спинной мозг
АРТКЫ БАРМАК — задний палец.
АРХЕОПТЕРИКС (*казылма кош*) — археоптерикс (первоптица)
АРЧА ЯСМЫК ЧЫПЧЫГЫ — чечевица арчовая
АСЫЛМА ОЯ — висячее гнездо
АСЫЛМА ТУТЫЙ КОШЛАР — попугаи висячие
АСЫЛТАШ ТӨСЛЕ ЧЕБЕНКОШ — колибри топазо-рубиновый
АТА КАЗ — гусак
АТА ҮРДӘК — селезень
АУЛАУЧЫ КОШЛАР — птицы ловчие
АУЧЫЛЫК КОШЛАРЫ — птицы промысловые
АФРИКА КАРЧЫГАСЫ — чеглок африканский
АФРИКА ТАВИС КОШЫ — павлин африканский
АФРИКА ТӘВӘ КОШЫ — страус африканский
АФРИКА ТӘПИЧӘ АЯГЫ — лапчатоног африканский
АФРИКА ТӨН КҮГӘРЧЕНЕ — козодой африканский
АФРИКА ЯКАНАСЫ — якана африканская
АЧЫК АВЫЗЛЫ ЛӘКЛӘК — аист-разиня
АЧЫК ЗӘҢГӘР ТӨСЛЕ ЛОРИ — лори ультрамариновый
АШЛЫК ИБИСЫ — каравайка
АҢГЫРА КОШЛАР (*давыл кошларыннан*) — глупыши
АҢГЫРА КӨРӘН АКЧАРЛАК — крачка глупая бурая

## Б

БАБАКОШ — пеликан
БАБАКОШЛАР (*семьялык*) — пеликановые
БАБАКОШСЫМАННАР (*ишкәгаяклылар*) — пеликанообразные (веслоногие)



БАЙГЫШ (*мәче башлы ябалак*) — филин обыкновенный
БАЙГЫШЛАР (*ябалак кошларның бер ыругы*) — филины
БАЙРАКЛЫ ЧЕБЕНКОШ — колибри-знаменосец
БАКААВЫЗЛАР (*төн күгәрченнәре*) — лягушкороты, козодои
БАКЛАН (*су кошы*) — баклан
БАКЛАННАР (*семьялык*) — баклановые
БАКЧА КАМЫШ ЧЫПЧЫГЫ — камышевка садовая
БАКЧА СОЛЫ ПЕСНӘГЕ — овсянка садовая
БАКЧА ЧЫПЧЫГЫ — славка садовая
БАКЫР ТӨСЛЕ ТУКРАН — дятел медный
БАЛАН ЧЫПЧЫГЫ (*карабүрек*) — снегирь
БАЛА ЧЫГАРУЧЫ КОШЛАР — выводковые птицы
БАЛАШАР — медоед
БАЛДАКСЫМАН КИМЕРЧӘК — хрящ перстневидный
БАЛИМӘР КОШЛАР — медососовые
БАЛ КҮРСӘТКЕЧ КОШЛАР (*семьялык*) — медоуказчиковые
БАЛОБАН (*лачын төре*) — балобан
БАЛТАЧЫК (*ишкәкканатлылардан*) — топорик
БАЛЫК АШАУЧЫ КОШЛАР — птицы рыбоядные
БАЛЫК БАЙГЫШЫ — филин рыбный
БАНАНАШАРЛАР (*кәккүкләр отрядыннан*) — бананоеды
БАНКИВ (*куаклык*) ТАВЫГЫ — банкивская (кустарниковая) курица
БАНКИВ ӘТӘЧЕ (*кыргавыллардан*) — банкивский петух
БАННЕРМАН ТУРАКОСЫ (*күкесыманнардан*) — турако Баннермана
БАРМАКЛАР БУЫНЫ — фаланга пальцев
БАСУ ТУРГАЕ (*сабан тургае*) — жаворонок полевой
БАШ АРТЫ БҮЛТӘЙМӘСЕ — затылочный мыщелок
БЕЗКОЙРЫК (*үрдәк төре*) — шилохвостка
БЕЗТОМШЫК (*ужым шөлдиләре ыругы*) — шилоклювка
БЕЗТОМШЫКЛЫЛАР — шилоклювые
БЕНГАЛИЯ ГРИФЫ — гриф бенгальский
БЕР ГЕНӘ АНА ЗАТ БЕЛӘН ЯШӘҮЧЕ АТА КОШЛАР — моногамные птицы
БЕРГӘ ЯШӘҮЧЕ КОШЛАР — колониальные птицы
БЕР ОЯ БАЛА КОШЧЫКЛАР — выводок птенцов
БЕТЕП БАРУЧЫ КОШЛАР — птицы исчезающие
БИБЕК (*тәкәрлек*) — чибис, пигалица
БИЗЧЕЛ АШКАЗАНЫ — желудок железистый
БИЗӘКЛЕ ЧУЛЛЫКЛАР — бекасы цветные
БИЗӘКЛЕ ҺИНД ТӘКӘРЛЕГЕ — чибис индийский украшенный
БИТ ДИСКЫ — лицевой диск
БИЮЧЕ ТАШ ЧЫПЧЫГЫ — каменка-плясунья

БОЛЫН КАРЛЫГАЧЫ (*шөлдиләрдән*) — тиркушка луговая, ласточка луговая
БОЛЫН КАРЧЫГАСЫ — лунь луговой
БОЛЫН КУПШЫСЫ (*дроздлардан*) — чекан луговой
БОЛЫН ТУРГАЕ — конёк луговой
БОРЫНГЫ АКЧАРЛАК — чайка реликтовая
БОЖЫР — рябчик
БРОНЗА КАНАТЛЫ ҺИНД ЯКАНАСЫ (*шөлдиләрдән*) — якана индийская, якана бронзовокрылая
БУЙ-БУЙЛЫ ТЫЧКАН-КОШ — птица-мышь полосатая
БУЙ-БУЙЛЫ ЯР ЧЫПЧЫГЫ (*кыштума*) — зимородок полосатый
БУЙВОЛ КОШЛАРЫ (*тукыр кошлардан*) — буйволовы птицы (ткачиковые)
БУЙВОЛ СЫЕРЧЫГЫ (*үгез чукучы*) — буйволов скворец (волоклюй)
БУРГОМИСТР (*котып акчарлагы*) — бургомистр, полярная чайка
БЫЛБЫЛЛАР (*кыска бармаклы сандугачлар*) — бюльбюли, коротколапые дрозды
БЫТБЫЛДЫК (*бүдәнә*) — перепел, перепёлка
БӘЛӘКӘЙ ШӨЛДИ — кроншнеп-малютка
БӨДРӘ БАБАКОШ — пеликан кудрявый
БӨРКЕТ — беркут
БӨРТЕГАШАР КОШЛАР — птицы зерноядные
БӨҖӘГАШАР КОШЛАР — птицы насекомоядные
БҮДӘНӘ (*бытбылдык*) — перепел
БҮДӘНӘ КАРЧЫГАСЫ (*кечкенә карчыга*) — ястреб-перепелятник, ястреб малый
БҮКСӘ — зоб
БҮКСӘЧ КҮГӘРЧЕННӘР — дутыши, голуби дутыши
БҮКСӘЧ ШӨЛДИ — кулик-дутыш
БҮЛТӘЙМӘ — мыщелок
БҮРЕК (*кошларда*) — хохолок
БҮРЕКЛЕ БАКЛАН — баклан хохлатый
БҮРЕКЛЕ КАРАГАЙ ҮРДӘК — чернеть хохлатая
БҮРЕКЛЕ КАРИАМА (*торнасыманнардан*) — кариама хохлатая
БҮРЕКЛЕ КЕРӘШӘЛӘР — стрижи хохлатые
БҮРЕКЛЕ КҮКЕ — кукушка хохлатая
БҮРЕКЛЕ ПЕСНӘК — синица хохлатая
БҮРЕКЛЕ ТИНАМУ — тинаму хохлатый
БҮРЕКЛЕ ТУРАКО — турако хохлатый
БҮРЕКЛЕ ТУРГАЙ — жаворонок хохлатый
БҮРЕКЛЕ ШӨПШӘАШАР — осоед хохлатый



БҮРЕКЛЕ ЯБАЛАКЧЫ ТӨН КҮГӘРЧЕНЕ — козодой совиный хохлатый
БҮРЕКЛЕ ЯР ЧЫПЧЫГЫ — зимородок хохлатый
БҮТӘКӘ — желудок мускульный

## В

ВАК БӨРКЕТЛӘР — подорлики-крикуны
ВАК ЧЕБЕНЧЕ — мухоловка малая
ВАК ЯБАЛАКЧЫКЛАР — сычики
ВАК ЯҢГЫР ЧЫПЧЫГЫ — зуёк малый
ВАНГАЛАР (*чыпчыксыманнардан*) — ванговые
ВЕРТИКАЛЬ КҮЧЕП ЙӨРҮЛӘР — вертикальные кочёвки
ВИРЕОННАР (*каракошларга охшаган кошлар*) — виреоновые

## Г

ГАВАЙ БАЛАШАРЛАРЫ (*сайрар чыпчыклар семьялыгы*) — гавайские цветочницы
ГАВАЙ КАЗАРКАСЫ — казарка гавайская
ГАГА (*диңгез үрдәге*) — гага
ГАГАРА (*диңгез кошы*) — гагара
ГАГАРАСЫМАННАР (*отряд*) — гагарообразные
ГАГАРКА (*ишкәкканатлылардан*) — гагарка
ГАДИ АЛА ЧУМГАЛАК (*үрдәкләр төре*) — гоголь обыкновенный
ГАДИ БАЙГЫШ — филин обыкновенный
ГАДИ ГАГА — гага обыкновенная
ГАДИ ДРОНТ (*додо*) — дронт обыкновенный (додо)
ГАДИ ДҮДӘК (*дала күркәсе*) — дрофа обыкновенная
ГАДИ ЕЛАК КАРЧЫГА — канюк обыкновенный (сарыч)
ГАДИ ЕЛАНМУЕН — змеешейка обыкновенная
ГАДИ ЙӨГЕРЕК ШӨЛДИ — бегунок обыкновенный
ГАДИ КАРАКАРА (*каранчо*) — каракара обыкновенная, каранчо
ГАДИ КЫРГАВЫЛ — фазан обыкновенный
ГАДИ МИСЫР ТАВЫГЫ — цесарка обыкновенная
ГАДИ СОЛЫ ЧЫПЧЫГЫ — овсянка обыкновенная
ГАДИ СЫЕРЧЫК — скворец обыкновенный
ГАДИ ТАВИС КОШ — павлин обыкновенный
ГАДИ ТАШ ЧЫПЧЫГЫ — каменка обыкновенная
ГАДИ ТӘВӘ КОШЫ — нанду обыкновенный

ГАДИ ТӨН КҮГӘРЧЕНЕ — козодой обыкновенный
ГАДИ УРМАН КҮГӘРЧЕНЕ — горлица обыкновенная
ГАДИ УТКОЙРЫК (*такырбаш*) — горихвостка обыкновенная, лысушка
ГАДИ ЧИКЕРТКӘ ЧЫПЧЫК — сверчок обыкновенный
ГАДИ ЧУЛЛЫК (*шөлдиләр төре*) — бекас обыкновенный
ГАДИ ЯБАЛАКЧЫК — совка обыкновенная (сплюшка, зорька)
ГАДИ ЯР ЧЫПЧЫГЫ — зимородок обыкновенный
ГАДИ ЯСМЫК ЧЫПЧЫГЫ — чечевица обыкновенная
ГАИЧКА (*песнәкләрдән*) — гаичка
ГАЛАПАГОС ПИНГВИНЫ — пингвин галапагосский
ГАЛАПАГОС ЧЫПЧЫКЛАРЫ (*Дарвин чыпчыклары*) — галапагосские вьюрки, Дарвиновы вьюрки
ГАЛСТУКЛЫ ШӨЛДИ — галстучник (зуёк)
ГАРПИЯ-МАЙМЫЛАШАР (*карчыгасыманнардан*) — гарпия-обезьяноед
ГАРШНЕП (*шөлдиләрдән*) — гаршнеп
ГВАТЕМАЛА КВЕЗАЛЫ — квезал гватемальский
ГЕСПЕРОРНИССЫМАННАР (*акбур чоры кошлары*) — гесперорнисообразные (птицы мелового периода)
ГОАЦИН (*кәккүкләрдән*) — гоацин
ГОККО (*кракс*) — гокко, кракс
ГОМОЙТЕРМЛЫК (*тәндә даими температура*) — гомойтермность
ГРИФ-АНА КҮРКӘ — гриф-индейка
ГРИФСЫМАН ДИҢГЕЗ БӨРКЕТЕ (*пальма грифы*) — грифовый орлан, пальмовый гриф
ГРИФ-УРУБУ — гриф-урубу
ГУАНО (*диңгез кошлары тизәге*) — гуано
ГУАХАРО (*симез кошлар*) — гуахаро, жиряки
ГУЛЬДОВ АМАДИНАСЫ — амадина Гульдова
ГҮЗӘЛ АМАЗОНА (*тутый кош төре*) — амазона великолепная
ГҮЗӘЛ ТУТЫЙ КОШЛАР — попугаи благородные, ожерельевые

## Д

ДАВЫЛ КОШЛАРЫ (семьялык) — буревестниковые, альбатросовые
ДАВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕ — буревестник
ДАВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕСЫМАННАР (*көпшәборынлылар*) — буревестникообразные, трубконосые
ДАЛА БӨРКЕТЕ — орёл степной
ДАЛА КАРЧЫГАСЫ — лунь степной



ДАЛА КҮГӘРЧЕНЕ — копытка, саджа
ДАЛА КҮГӘРЧЕННӘРЕ (*семьялык*) — рябки, рябковые
ДАЛА ТАВЫГЫ — тетерев степной
ДАЛА ТИРКУШКАСЫ (*шөлдиләрдән*) — тиркушка степная
ДАЛА ТОРНАСЫ — авдотка
ДАЛА ТОРЫМТАЕ — пустельга степная
ДАЛА ТУРГАЕ — жаворонок степной
ДАРВИН НАНДУЫ (*тәвә кошы*) — нанду Дарвина
ДАУРИЯ ТОРНАСЫ — журавль даурский
ДАУРИЯ ЧӘҮКӘСЕ — галка даурская
ДЕККЕН ТОКОСЫ (*кара томшыклы токо*) — токо Деккена, токо черноклювый
ДЕКОРАТИВ КҮГӘРЧЕННӘР — голуби декоративные
ДЖЕК (*күяз дүдәк*) — джек, дрофа-красотка
ДЖУНГЛИ ТАВЫГЫ — джунглевая курица
ДИВАР ҮРМӘЛӘЧЕ — стенолаз
ДИҢГЕЗ АКЧАРЛАГЫ — чайка морская
